Республика Татарстан

**Г Л А В А**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА**

Татарстан Республикасы

**«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ**
**Б А Ш Л Ы Г Ы**
**ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ**

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## К А Р А Р

«28» 12 2006 г.

№ 146

Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында

Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр белгечләренә торак мәйданының Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә чыгымнарның 100 %ы күләмендә социаль ярдәм чараларын һәм коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын бирүне түбәндәге гражданнар категорияләренә билгеләргә:

педагогик хезмәткәрләргә, мәдәният хезмәткәрләренә;

социаль хезмәтләр системасының социаль хезмәткәрләренә;

табибларга, провизорларга, урта медицина яисә фармацевтика белеме булган хезмәткәрләргә, медицина хезмәткәрләренә

турыдан-туры социаль-медицина хезмәте күрсәтү белән шөгыльләнүче социаль хезмәтләрнең дәүләт системасы;

пенсиягә чыккан хезмәткәрләргә, әгәр алар медицина учреждениеләрендә, мәгариф учреждениеләрендә, мәдәният учреждениеләрендә, авыл җирендә урнашкан социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә 10 елдан да ким эшләмәсәләр һәм шунда яшәсәләр.

2. Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирү белән бәйле чыгымнарны әлеге максатларга учреждениеләрнең чыгымнары сметасында каралган акчалар хисабына гамәлгә ашырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Финанс-бюджет палатасы» МУ рәисе Р.Х. Хәмидуллинга йөкләргә.

«Лениногорск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры И.А.САДРИЕВ

Р.Х.Хәмидуллин
5-18-25